**Казан шәһәре Башкарма комитетының**

**2026 елның 7 маендагы 1580 номерлы карары**

## Казан шәһәре территориясендә гаиләдә белем алу һәм мөстәкыйль белем алу формаларында гомуми белем алу турында

2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә мәгариф турында»гы федераль законның 17, 34, 58, 63 статьялары, Россия Мәгариф һәм фән министрлыгының 2013 елның 15 ноябрендәге НТ-1139/08 номерлы «Гаилә формасында белем алуны оештыру турында»гы хаты нигезендә, Россия Федерациясе гражданнарына гомуми белем алу формасын сайлау хокукын тәэмин итү максатыннан **карар бирәм**:

1. Казан шәһәре территориясендә гаиләдә белем алу һәм мөстәкыйль белем алу формаларында гомуми белем алу турында нигезләмәне (1 номерлы кушымта) расларга.

2. Баланың гаиләдә белем алу формасында (2 номерлы кушымта) һәм мөстәкыйль белем алу формасында (3 номерлы кушымта) гомуми белем алуын раслау турында хәбәрнамәләр формаларын расларга.

3. Балигъ булмаган укучыларның ата-аналары (законлы вәкилләре), төп гомуми белем алганнан соң яисә унсигез яше тулганнан соң белем алучылар өчен хат-аңлатма формаларын расларга (4 номерлы кушымта).

4. Түбәндәгеләрне гамәлдән чыккан дип танырга:

4.1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2018 елның 30 мартындагы 1158 номерлы «Казан шәһәре территориясендә гаиләдә белем алу һәм мөстәкыйль белем алу формаларында гомуми белем алу турында» карарын;

4.2. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2018 елның 22 июнендәге 3659 номерлы «Казан шәһәре Башкарма комитетының 2018 елның 30 мартындагы 1158 номерлы карарына үзгәреш кертү турында»гы карарын;

4.3. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2022 елның 19 апрелендәге 1158 номерлы «Казан шәһәре Башкарма комитетының 2018 елның 30 мартындагы 1158 номерлы “Казан шәһәре территориясендә гаиләдә белем алу

һәм мөстәкыйль белем алу формаларында гомуми белем алу турында”гы карарына үзгәреш кертү хакында»гы карарын.

5. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары А.И.Абзаловка йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2026 елның 7 маендагы
1580 номерлы карарына
1 номерлы кушымта

**Казан шәһәре территориясендә гаиләдә белем алу
һәм мөстәкыйль белем алу формаларында
гомуми белем алу турында
нигезләмә**

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге нигезләмә гаиләдә белем алу һәм мөстәкыйль белем алу формаларында гомуми белем алу, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә яшәүче һәм гаиләдә белем алу һәм мөстәкыйль белем алу формасында гомуми белем алучы гражданнарны исәпкә алу тәртибен билгели һәм педагогик хезмәткәрләрнең, балаларның әти-әниләренең (законлы вәкилләренең) яки экстерннарның түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүдә компетентлылыгын арттыру максатыннан эшләнде:

- белем бирү оешмасыннан читтә (гаиләдә белем алу яисә мөстәкыйль белем алу формасында) башлангыч гомуми, төп гомуми яисә урта гомуми белем бирү буенча мәгариф программаларын үзләштерергә теләгән гражданнардан яки балаларның әти-әниләреннән (законлы вәкилләреннән) гариза килеп ирешкәндә, педагогик хезмәткәрләр тарафыннан тиешле гамәлләр башкару исемлеген һәм тәртибен билгеләү;

- мәгариф өлкәсендә үз бурычлары һәм хокуклары, баланың бурычлары һәм хокуклары турында мәгълүмат алу;

- экстерннарны укыту, тәрбияләү, үстерү, социализацияләү.

1.2. Гаиләдә белем алуны, мөстәкыйль белем алуны оештыру белән бәйле мәсьәләләр түбәндәге Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы законнары нормалары белән тәртипкә салынган:

- Россия Федерациясе Конституциясе;

- 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә мәгариф турында»гы федераль закон (алга таба – 273-ФЗ номерлы федераль закон);

- Россия Федерациясе Ґаилә кодексы;

- Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2023 елның 11 октябрендәге 1678 номерлы «Белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмалар тарафыннан мәгариф программаларын гамәлгә ашырганда электрон ресурслардан файдаланып укытуны, дистанцион белем бирү технологияләрен куллану кагыйдәләрен раслау турында»гы карары;

- Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгының 2020 елның 2 сентябрендәге 458 номерлы «Башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирүнең мәгариф программалары буенча укырга кабул итү тәртибен раслау турында»гы әмере;

- Казан шәһәре Башкарма комитетының 2021 елның 29 декабрендәге 3515 номерлы карары (аңа Казан шәһәре Башкарма комитетының 2023 елның 28 мартындагы 895 номерлы, 2025 елның 17 гыйнварындагы 41 номерлы, 2025 елның 25 июлендәге 2357 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган Казан шәһәрендә гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыра торган муниципаль мәгариф оешмаларына алу турында гаризалар кабул итү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты;

- Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгының 2023 елның 6 апрелендәге 240 номерлы «Укучыларны башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирүнең мәгариф программалары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы бер оешмадан тиешле дәрәҗәдәге һәм юнәлештәге мәгариф программалары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы башка оешмаларга күчерү тәртибен һәм шартларын раслау турында»гы әмере;

- Россия Мәгариф һәм фән министрлыгының 2010 елның 17 декабрендәге 1897 номерлы «Төп гомуми белем бирүнең федераль дәүләт белем бирү стандартын раслау турында»гы әмере;

- Россия Мәгариф һәм фән министрлыгының 2012 елның 17 маендагы 413 номерлы «Урта гомуми белем бирүнең федераль дәүләт белем бирү стандартын раслау турында»гы әмере;

- Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгының 2021 елның 31 маендагы 286 номерлы «Башлангыч гомуми белем бирүнең федераль дәүләт белем бирү стандартын раслау турында»гы әмере;

- Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгының 2021 елның 31 маендагы 287 номерлы «Төп гомуми белем бирүнең федераль дәүләт белем бирү стандартын раслау турында»гы әмере;

- Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгының 2021 елның 22 мартындагы 115 номерлы «Төп гомуми белем бирү программалары –

Документ создан в электронной форме. № 56882-Инф от 25.05.2026. Исполнитель: Переводчики
Страница 5 из 21. Страница создана: 23.05.2026 12:56
ЕМСЭД

башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирүнең мәгариф программалары буенча белем бирү эшчәнлеген оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында»гы әмере;

- Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгының һәм Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек федераль хезмәтенең 2023 елның 4 апрелендәге 232/551 номерлы «Төп гомуми белем бирүнең мәгариф программалары буенча дәүләт йомгаклау аттестациясен үткәрү тәртибен раслау турында»гы әмере;

- Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгының һәм Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек федераль хезмәтенең 2023 елның 4 апрелендәге 232/552 номерлы «Урта гомуми белем бирүнең мәгариф программалары буенча дәүләт йомгаклау аттестациясен үткәрү тәртибен раслау турында»гы әмере;

- Россия Фән һәм югары белем бирү министрлыгы һәм Россия Мәгариф Министрлыгының 2020 елның 30 июлендәге 845/369 номерлы «Белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешма тарафыннан белем алучыларның уку предметларын, курсларын, дисциплиналарын (модульләрен), практикасын, белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы башка оешмаларда өстәмә белем бирү программаларын үзләштерү нәтиҗәләрен исәпкә алу тәртибен раслау турында»гы әмере;

- 2013 елның 22 июлендәге 68-ТРЗ номерлы «Мәгариф турында»гы Татарстан Республикасы законы;

- ел саен Татарстан Республикасы законы белән (2024 елда – 2024 елның 3 октябрендәге 74-ТРЗ номерлы «2025 елга, 2026 һәм 2027 елларның план чорына Татарстан Республикасында гомуми белем бирү оешмаларында һәм һөнәри белем бирү оешмаларында һәркем ала алырлык һәм бушлай башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем, шулай ук өстәмә белем алуга хокукларны гамәлгә ашыруның дәүләт гарантияләрен финанс белән тәэмин итү нормативларын раслау турында»гы Татарстан Республикасы законы белән) раслана торган агымдагы елга һәм план чорына Татарстан Республикасында гомуми белем бирү оешмаларында һәм һөнәри белем бирү оешмаларында һәркем ала алырлык һәм бушлай башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем, шулай ук өстәмә белем алуга хокукларны гамәлгә ашыруның дәүләт гарантияләрен финанс белән тәэмин итү нормативлары.

1.3. 273-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә, шәхеснең ихтыяҗларын һәм мөмкинлекләрен исәпкә алып, төрле формаларда белем алырга мөмкин: белем бирү эшчәнлеге алып баручы оешмаларда; белем бирү эшчәнлеге алып баручы оешмалардан читтә, гаиләдә белем алу формасында (башлангыч гомуми, төп гомуми белем) һәм мөстәкыйль белем алу формасында (урта гомуми белем).

Гаиләдә белем алу яисә мөстәкыйль белем алу формасында белем алу, тиешле мәгариф программасы буенча дәүләт аккредитациясе булган гомуми белем бирү оешмасында (алга таба – Оешма) арадаш һәм (яисә) дәүләт йомгаклау аттестациясен экстерн рәвештә узып, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белемнең гомуми белем бирү программаларын мөстәкыйль өйрәнүне күздә тота.

1.4. Балигъ булмаган укучының әти-әнисе (законлы вәкилләре), белем бирү оешмасыннан читтә белем алу формасын сайлап, баланың гомуми белем алуын тәэмин итү буенча мөстәкыйль шартлар тудыру йөкләмәләрен үз өстенә ала.

1.5. Гамәлдәге законнар нигезендә белем алуның төрле формаларын һәм укыту формаларын берләштерү рөхсәт ителә (273-ФЗ номерлы федераль законның 17 статьясындагы 4 өлеше). Берләштерү модельләрен гамәлгә ашыру, атап әйткәндә, Оешмага йөреп белем алуны һәм гаиләдә белем алу яки мөстәкыйль белем алу формаларын берләштергәндә, төп гомуми белем бирү программаларын тормышка ашыру моделе гамәлдәге законнар кысаларында кабул ителгән локаль акт нигезендә Оешма тарафыннан билгеләнә. Оешмага йөреп белем алуны һәм гаиләдә белем алуны (мөстәкыйль белем алуны) берләштерү укучыны Оешмадан чыгаруны күздә тотмый.

1.6. Гаиләдә белем алу формасында яки мөстәкыйль белем алу формасында төп гомуми белем алучы зат үз карары яки, балигъ булмаган укучының фикерен исәпкә алып, әти-әнисе (законлы вәкиле) карары буенча белем алуның теләсә кайсы этабында Оешмада белем алуны дәвам итәргә хокуклы яисә аның белем алу һәм укыту формаларын берләштерүгә хокукыннан файдаланырга хакы бар (273-ФЗ номерлы федераль законның 17 статьясындагы 4 бүлек, 44 статьясындагы 3 бүлекнең 2 пункты).

1.7. Гаиләдә белем алу формасында башлангыч гомуми, төп гомуми белемнең һәм мөстәкыйль белем алу формасында урта гомуми белемнең төп гомуми белем бирү программалары буенча гомуми белем алу бердәм федераль дәүләт белем бирү стандартлары белән билгеләнә.

1.8. Гаиләдә белем алу һәм мөстәкыйль белем алу формаларында белем алучы укучыларны исәпкә алуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Мәгариф идарәсенең район мәгариф бүлекләре гамәлгә ашыра.

1.9. Мәгариф өлкәсендәге җирле үзидарә органнары, белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмалар гаиләдә белем алу яки мөстәкыйль белем алу формаларында белем алучы балигъ булмаган гражданнар турында мәгълүматны күзәтчелек органнарына, хокук саклау органнарына, шулай ук

балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясенә тапшырырга хокуклы.

## II. Гаиләдә белем алу һәм мөстәкыйль белем алу формаларында гомуми белем алу тәртибе

2.1. Балигъ булмаган балаларның әти-әниләре (законлы вәкилләре), төп гомуми белем алганнан соң яки унсигез яше тулганнан соң укучы гомуми белем алуның теләсә кайсы дәрәҗәсендә һәм укуның теләсә кайсы этабында гаиләдә белем алуны, мөстәкыйль белем алуны сайларга хокуклы.

2.2. Балигъ булган гражданин яисә балигъ булмаган укучының әти-әнисе (законлы вәкилләре) гаиләдә белем алу яисә мөстәкыйль белем алу формасында башлангыч гомуми, төп гомуми яисә урта гомуми белем алу формасын сайлауга бәйле рәвештә укучыны Оешмадан чыгару турында гариза белән Оешмага мөрәҗәгать итәләр.

2.3. Әлеге гариза нигезендә Оешма өч эш көне эчендә укучыны чыгару турында боеру акты чыгара һәм, гаиләдә белем алу яисә мөстәкыйль белем алу формасында гомуми белем алу формасын сайлап алуга бәйле рәвештә, укучыны Оешмадан чыгару турында мәгариф бүлегенә хәбәр итә.

2.4. Гаиләдә белем алу яисә мөстәкыйль белем алу формасында гомуми белем алу формасын сайлап алуга бәйле рәвештә укучыны Оешмадан чыгарганда, Оешма балигъ булмаган укучының әти-әнисенә (законлы вәкилләренә), төп гомуми белем алганнан соң яки унсигез яше тулганнан соң укучыга, мәктәптән читтә белем алуны дәвам иткән очракта, ел саен арадаш аттестация узу һәм Казан шәһәре Башкарма комитеты Мәгариф идарәсенең район мәгариф бүлегенә хәбәр итү зарурлыгы турында язма рәвештә хәбәр итә.

2.5. Гаиләдә белем алу формасына яисә мөстәкыйль белем алуга күчү сәбәпле Оешмадан чыгарылганнан соң, балигъ булмаган укучының әти-әнисе (законлы вәкилләре), төп гомуми белем алганнан соң яисә унсигез яше тулганнан соң белем алучы 15 календарь көн эчендә түбәндәгеләрне башкарырга тиешләр:

2.5.1. укучы арадаш һәм (яисә) дәүләт йомгаклау аттестациясен экстерн сыйфатында, шул исәптән алар яши торган территориядәге муниципаль районның яисә шәһәр округының җирле үзидарә органы тәкъдимнәре нигезендә узачак оешманы сайларга. Балигъ булмаган укучыларның әти-әнисе (законлы вәкилләре), төп гомуми белем алганнан соң яисә унсигез яше тулганнан соң белем алучы теләге буенча аттестация узу өчен белем бирү оешмасы бер уку

елына, гомуми белем алуның барлык чорына яисә конкрет аттестация узу чорына билгеләнергә мөмкин;

2.5.2. гаиләдә белем алу яисә мөстәкыйль белем алу формасында гомуми белем алу формасын сайлау һәм сайлау сәбәпләре турында Казан шәһәре Башкарма комитеты Мәгариф идарәсенең яшәү урыны буенча район мәгариф бүлегенә хәбәр итәргә. Хәбәрнамәгә укучы экстерн рәвешендә арадаш һәм (яисә) дәүләт йомгаклау аттестациясен узачак Оешманың арадаш аттестациясен оештыру турындагы әмере күчермәсен әлеге карарның 2 номерлы, 3 номерлы кушымталарындагы форма буенча теркәп бирү зарур:

2.5.2.1. документларның төп нөсхәләрен (балигъ булмаган укучының әтисе яки әнисе (законлы вәкиле) паспорты, укучының туу турында таныклыгы яисә паспорты, укучыны яшәү урыны буенча теркәү турында документ) тапшырып, шәхсән барып, язма рәвештә;

2.5.2.2. Казан шәһәре Башкарма комитеты Мәгариф идарәсенең Интернет аша кабул итү бүлмәсе аша Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе башлыгы адресына электрон рәвештә (https://obrazovanie.kzn.ru), Россия Федерациясенең бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында идентификация узып, документларның күчермәләрен (балигъ булмаган укучының әтисе яисә әнисе (законлы вәкиле) паспорты, туу турында таныклык яисә укучының паспорты, укучыны яшәү урыны буенча теркәү турында документ) теркәп;

2.5.3. балигъ булмаган затның әти-әнисе (законлы вәкилләре) арадаш һәм (яисә) йомгаклау аттестациясен узу өчен Оешмага беркетү турында белешмәләр бирүдән баш тарткан, белешмәләр булмаган яисә экстерн лицензиясе һәм (яисә) аккредитациясе булмаган Оешмага беркетелгән очракта, мәгариф бүлеге арадаш һәм (яисә) йомгаклау (дәүләт йомгаклау) аттестациясен узу өчен башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирүнең мәгариф программаларын гамәлгә ашыруга лицензиясе һәм белем бирүнең һәр дәрәҗәсе буенча дәүләт аккредитациясе турында таныклыгы булган мәгариф оешмасын сайлау кирәклеге турында аңлата (шәхсән килгән очракта – телдән яисә электрон хәбәр җибәргән очракта – язмача) (әлеге карарга 4 номерлы кушымта).

2.6. Гомуми белем бирү оешмасыннан читтә белем алуны дәвам иткән очракта, балигъ булмаган укучыларның әти-әнисе (законлы вәкилләре), төп гомуми белем алганнан соң яисә унсигез яше тулганнан соң белем алучы, уку елы башланырга кимендә унбиш календарь көн кала, Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе башлыгы адресына язма рәвештә (шәхсән килеп) яки Казан шәһәре Башкарма комитеты Мәгариф идарәсенең Интернет аша кабул

итү сәхифәсе (https://obrazovanie.kzn.ru) аша электрон рәвештә, Россия Федерациясенең бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында идентификация узып, әлеге карарга 2 номерлы, 3 номерлы кушымталардагы форма буенча Казан шәһәре Башкарма комитеты Мәгариф идарәсенең яшәү урыны буенча район мәгариф бүлегенә гаиләдә белем алу яисә мөстәкыйль белем алу формасында гомуми белем алу формасын сайлау турында кабат хәбәр итәргә тиеш. Хәбәрнамәгә укучы экстерн рәвешендә арадаш һәм (яки) дәүләт йомгаклау аттестациясен узачак Оешманың арадаш аттестацияне оештыру турындагы әмере күчермәсе теркәп бирелә.

2.7. Гаиләдә белем алу яисә мөстәкыйль белем алу формасында белем алу формасын сайлаган очракта, Оешма һәм балигъ булмаган укучының әти-әнисе (законлы вәкилләре), төп гомуми белем алганнан соң яисә унсигез яше тулганнан соң белем алучы арасындагы мөнәсәбәтләр Оешма җитәкчесенең экстерн рәвешендә арадаш һәм (яисә) дәүләт йомгаклау аттестациясен оештыру турындагы гаризалары нигезендә өч эш көне эчендә бастырып чыгарыла торган әмере белән җайга салына.

2.8. Аттестацияне оештыру һәм үткәрү өчен Оешма:

- бер уку елына,
- тиешле мәгариф программасы буенча белем алуның барлык чорына,
- билгеле бер аттестация үтү чорына билгеләнә ала.

2.9. Әмердә укучы арадаш һәм (яисә) дәүләт йомгаклау аттестациясен узачак белем бирү процессының уку-укыту курслары, предметлары, дисциплиналары (модульләре) исемлеге, шулай ук аларны уздыру вакытлары (Оешманың локаль акты нигезендә) күрсәтелә.

2.10. Әмернең күчермәсе балигъ булмаган укучының әти-әнисенә (законлы вәкилләренә) яки төп гомуми белеме булган яисә унсигез яше тулган укучыга бирелә.

2.11. Экстерннар өчен, алар белән яисә балигъ булмаганнарның әти-әнисе (законлы вәкилләре) белән килештереп, уку планында билгеләнгән формаларда һәм Оешманың локаль норматив актында билгеләнгән тәртиптә үткәрелә торган арадаш аттестация уздыру графигы раслана. Әлеге локаль норматив акт белән каршылыксыз танышырга мөмкин булырга тиеш, шул исәптән ул Оешманың «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге сайтында да урнаштырылырга тиеш.

2.12. Арадаш һәм (яисә) дәүләт йомгаклау аттестациясен узу чорына гаиләдә белем алу яисә мөстәкыйль белем алу формасында гомуми белем алучы

бала белем бирү эшчәнлеген дәүләт аккредитациясе булган тиешле белем бирү программасы буенча гамәлгә ашыручы Оешмага экстерн рәвештә кабул ителә.

2.13. Кабул итү балигъ булган гражданинның яисә балигъ булмаган баланың әти-әнисенең (законлы вәкилләренең) шәхси гаризасы буенча гамәлгә ашырыла. Арадаш һәм (яисә) йомгаклау (дәүләт йомгаклау) аттестациясен узуны оештыру өчен нигез булып Оешманың баланы экстерн рәвештә кабул итү турындагы боеру акты тора.

2.14. Оешма:

2.14.1. Казан шәһәре Башкарма комитеты Мәгариф идарәсенең район мәгариф бүлегенә гаиләдә белем алу яисә мөстәкыйль белем алу формасында гомуми белем алучы укучының арадаш һәм (яисә) йомгаклау (дәүләт йомгаклау) аттестациясен узу өчен экстерн рәвештә кабул ителүе турында хәбәр итә;

2.14.2. экстернның шәхси эше булмаган очракта, арадаш һәм (яисә) йомгаклау (дәүләт йомгаклау) аттестациясен узу чорына документлар исемлеген («экстерн папкасын») рәсмиләштерә;

2.14.3. арадаш аттестация уздыру графигын раслый, аны төзегәндә укучының (Оешмага экстерн рәвешендә кабул ителгән) яшь һәм шәхси үзенчәлекләрен, әмма көненә бердән артык булмаган уку предметын (курсын) исәпкә алу тәкъдим ителә;

2.14.4. арадаш һәм (яисә) дәүләт йомгаклау аттестациясен уздыру чорына кабул итү турындагы әмер шартлары нигезендә белем алучыга Оешманың китапханәсендә булган дәреслекләрне һәм башка китапларны бушлай бирә;

2.14.5. укучыга, аның әти-әнисенә (законлы вәкилләренә) гомуми белем бирү программасын үзләштерү өчен кирәкле бушлай методик һәм консультатив ярдәм күрсәтә;

2.14.6. балигъ булмаган укучының әти-әнисе (законлы вәкилләре) яки төп гомуми белеме булган яисә унсигез яше тулган укучы гаризасы нигезендә арадаш һәм (яисә) дәүләт йомгаклау аттестациясе кысаларында тапшырыла торган фәннәр буенча бушлай консультацияләр уздыра. Консультацияләр саны Оешманың локаль акты белән билгеләнә;

2.14.7. укучылар тарафыннан практик һәм лаборатор эшләр башкару өчен шартлар тудыра;

2.14.8. башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирүнең федераль дәүләт белем бирү стандартлары нигезендә өйрәнү өчен мәҗбүри булган барлык укыту предметлары буенча Оешманың норматив актлары һәм локаль актлары нигезендә экстерн рәвештә арадаш һәм (яисә) дәүләт йомгаклау аттестациясе узу процессын оештыру өчен шартлар тудыра;

2.14.9. экстернның арадаш аттестациясен үткәрү беркетмәләрен алып бара;

2.14.10. Оешманың норматив актлары һәм локаль акты нигезендә укучының академик бурычын бетерү өчен шартлар булдыра һәм аны үз вакытында бетерүне контрольдә тота;

2.14.11. укучыга Оешмада укуны дәвам иттерү мөмкинлеген бирә.

2.15. Балигъ булмаган укучының әти-әнисе (законлы вәкилләре) белем алучыларга федераль дәүләт мәгариф стандартлары нигезендә төп белем бирү программасы буенча белем бирүнең тиешле дәрәҗәсендә һәм тиешле этабында гомуми белем алуны тәэмин итәргә тиеш.

2.16 Гаиләдә белем алу яисә мөстәкыйль белем алу формасында белем алучы балигъ булмаган укучы (әти-әнисе (законлы вәкилләры) карары буенча), төп гомуми белем алганнан соң яки 18 яше тулганнан соң укучы гомуми белемнең теләсә кайсы дәрәҗәсендә һәм укуның теләсә кайсы этабында белем алуны Оешмада, шул исәптән үзе арадаш аттестация узган Оешмада дәвам итәргә хокуклы (кабул итү өчен вакантлы урыннар булган очракта).

2.17. Бер яки берничә уку предметы, курслар, белем бирү программасының дисциплиналары (модульләре) буенча арадаш аттестация нәтиҗәләре канәгатьләнерлек булмау яисә, нигезле сәбәпләр булмаганда, арадаш аттестацияне узмау академик бурыч дип таныла. Укучы уку предметының, курсның, белем бирү программасы дисциплинасының (модуленең) аерым өлешен яисә тулы күләмен үзләштерүне дәвам итү өчен аны ябарга тиеш булачак.

2.18. Академик бурыч ябылмаган очракта, гаиләдә белем алу һәм мөстәкыйль белем алу формасында башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирүнең мәгариф программалары буенча белем алучы белем алуны гомуми белем бирү оешмасында дәвам итә (273-ФЗ номерлы федераль законның 58 статьясындагы 10 өлеше). Шул ук вакытта балигъ булмаган укучының әти-әнисе (законлы вәкилләре), төп гомуми белем алганнан соң яисә унсигез яше тулганнан соң белем алучы укуны дәвам итүнең түбәндәге вариантларыннан берсен сайларга хокуклы:

- кабат бер ел уку;

- психологик-медицина-педагогик комиссиянең тәкъдимнәре буенча адаптацияләнгән белем бирү программалары буенча укуга күчерү;

- шәхси уку планы (шул исәптән академик бурычны ябу өчен кирәкле чорны да үз эченә алган) буенча уку.

2.19. Экстернны арадаш аттестацияләүне гамәлгә ашырган Оешма Казан шәһәре Башкарма комитеты Мәгариф идарәсенең район мәгариф бүлегенә экстернның уку чоры (сыйныф) өчен фәннәр буенча академик бурычы булуы һәм

- арадаш аттестация узу өчен алдан беркетелгән оешмага (буш урын булган очракта);

- яшәү урыны буенча гомуми белем бирү оешмасына кабул итү юлы белән алга таба укытуны оештыру кирәклеге турында мәгълүмат җиткерә.

2.20. Оешмада укуны дәвам итү өчен гаиләдә белем алу яки мөстәкыйль белем алу формасында белем бирү программасын үзләштерүче затны Оешмага кабул итү Россия Мәгариф министрлыгының 2020 елның 2 сентябрендәге 458 номерлы әмере белән расланган Башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирүнең мәгариф программалары буенча укырга кабул итү тәртибе нигезендә гамәлгә ашырыла.

2.21. Гаиләдә белем алу яки мөстәкыйль белем алу формасында белем бирү программасын үзләштергәнннән соң, арадаш аттестацияне уңышлы узган очракта, экстернга Оешма тарафыннан мөстәкыйль билгеләнә торган үрнәк буенча белешмә бирелә (арадаш аттестация үткәрелгән предметлар, курслар, дисциплиналар (модульләр) исемлеген, белем бирү программасының (аның өлешенең) исемен күрсәтергә тәкъдим ителә).

2.22. Казан шәһәре Башкарма комитеты Мәгариф идарәсенең район мәгариф бүлекләре билгеләнгән вакытларда академик бурычын япмаган укучыларның гомуми белем бирү оешмасына йөреп белем алуларын дәвам итүләрен контрольдә тотуны тәэмин итәләр һәм әти-әнигә (законлы вәкилләргә) гомуми белем бирү оешмасыннан читтә белем бирү программасын үзләштерүне туктату турында  хәбәр итүне тәэмин итәләр.

2.21. Гаиләдә белем алу яки мөстәкыйль белем алу формасында гомуми белем бирү программасы буенча укучылар Оешманың локаль норматив актында күрсәтелгән шартлар нигезендә башка Оешмаларда уздырылган арадаш аттестация нәтиҗәләрен Оешма тарафыннан исәпкә алу хокукына ия.

2.24. Туры килүне билгеләү процедурасы, шул исәптән бәяләү үткәрелә торган очраклар һәм аны үткәрү формалары, дәүләт аккредитациясе булмаган оешмаларда укучылар тарафыннан узган уку предметларын үзләштерү нәтиҗәләрен исәпкә алу тәртибе Оешманың локаль норматив акты белән билгеләнә.

2.25. Әти-әниләр (законлы вәкилләр), төп гомуми белем алганнан соң яисә унсигез яше тулганнан соң гаиләдә белем алу яисә мөстәкыйль белем алу формасында белем алучы уку елы тәмамланганнан соң, әмма 31 майдан да соңга

калмыйча, Казан шәһәре Башкарма комитеты Мәгариф идарәсенең район мәгариф бүлегенә агымдагы уку елында арадаш аттестация узу турында белешмә тапшырырга тиеш.

2.26. Балигъ булмаган баланың әти-әнисе (законлы вәкилләре) тарафыннан гаиләдә белем алу формасында гомуми белем бирүнең мәгариф программаларын үзләштерүне оештыру өлешендә Россия Федерациясе законнары таләпләре үтәлмәгән очракта (Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә арадаш аттестация узудан баш тарту яисә аны узу турында мәгълүмат тапшырмау, дәүләт йомгаклау аттестациясен узудан баш тарту), 1 июльдән дә соңга калмыйча, Казан шәһәре Башкарма комитеты Мәгариф идарәсенең район мәгариф бүлеге тарафыннан түбәндәге чаралар башкарыла:

- балигъ булмаганнар эшләре буенча комиссияләр тарафыннан балаларга белем алуга, законнар буенча билгеләнгән тәртиптә төп гомуми яисә урта гомуми белем бирүнең мәгариф программалары буенча дәүләт йомгаклау аттестациясе узуга һәм төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү турында аттестат алуга каршылык тудыручы әти-әниләргә (законлы вәкилләргә) карата балигъ булмаганнарны укыту буенча бурычларын балигъ булмаганнарның әти-әниләре яисә башка законлы вәкилләре тарафыннан үтәмәү яисә тиешенчә үтәмәү турындагы мәсьәләне, шулай ук балигъ булмаганның һәркем ала алырлык һәм бушлай төп гомуми яисә урта гомуми белем алуга хокуклары бозылу өлешендә әти-әниләрне (законлы вәкилләрне) җаваплылыкка тарту турындагы мәсьәләне карап тикшерү инициативасы белән чыгу;

- закон буенча билгеләнгән тәртиптә күзәтү органнарына, хокук саклау органнарына булган хәл турында хәбәр итү;

- дәүләт яки муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында баланың һәркем ала алырлык һәм бушлай төп гомуми яки урта гомуми белем алу хокукы бозылу турында әти-әниләргә (законлы вәкилләргә) карата судка мөрәҗәгать итү инициативасы белән чыгу.

2.27. Уку елының төп гомуми белем бирү программасын барлык уку курслары, предметлар, дисциплиналар (модульләр) буенча уңышлы үзләштергән экстерн, арадаш аттестация нәтиҗәләренә нигезләнеп, гаиләдә белем алу яисә мөстәкыйль белем алу формасында гомуми белем алуны дәвам итәргә хокуклы. Ул бу хакта Казан шәһәре Башкарма комитеты Мәгариф идарәсенең яшәү урыны буенча район бүлегенә, шәхсән килеп, әлеге нигезләмәнең 2.5 һәм 2.6 пунктларында билгеләнгән тәртиптә арадаш аттестация нәтиҗәләрен алганнан соң җиде эш көне эчендә язмача хәбәр итәргә тиеш.

Документ создан в электронной форме. № 56882-Инф от 25.05.2026. Исполнитель: Переводчики
Страница 14 из 21. Страница создана: 23.05.2026 12:56
ЕМСЭД

2.28. Укучыларга төп гомуми һәм урта гомуми белемнең гомуми белем бирү программаларын үзләштерү үткәрү формалары һәм тәртибе мәгариф өлкәсендә дәүләт сәясәтен эшләү һәм норматив-хокукый җайга салу функцияләрен гамәлгә ашыручы федераль башкарма хакимият органы тарафыннан билгеләнә торган мәҗбүри дәүләт йомгаклау аттестациясе белән тәмамлана.

2.29. Дәүләт йомгаклау аттестациясен узу өчен Оешмага кабул итүгә гариза бирү вакыты:

- төп гомуми белем бирүнең мәгариф программалары буенча – рус теле буенча йомгаклау әңгәмәсе үткәрү көненә кадәр кимендә ике атна, әмма 1 марттан соңга калмыйча;

- урта гомуми белем бирүнең мәгариф программалары буенча – йомгаклау иншасын (изложениесен) үткәргәнчегә кадәр кимендә ике атна, әмма 1 февральдән соңга калмыйча.

2.30. Дәүләт йомгаклау аттестациясендә катнашу турындагы гаризалар экстерннар тарафыннан экстерннар сайлаган Оешмага тапшырыла.

2.31. Һәр уку елында арадаш аттестациядә федераль дәүләт мәгариф стандартлары нигезендә укыту өчен мәҗбүри булган барлык уку предметлары буенча кимендә канәгатьләнерлек билгесе алган очракта, шулай ук төп гомуми белем бирүнең мәгариф программалары буенча дәүләт йомгаклау аттестациясе үткәрелгәндә – рус теленнән йомгаклау әңгәмәсе өчен «зачет» билгесе яки урта гомуми белем бирүнең мәгариф программалары буенча дәүләт йомгаклау аттестациясе үткәрелгәндә – йомгаклау иншасы (изложениесе) өчен «зачет» билгесе куелса, экстерннарга дәүләт йомгаклау аттестациясен узарга рөхсәт бирелә.

2.32. Укучы, белем бирү программаларын үзләштергәннән соң, дәүләт йомгаклау аттестациясен уңышлы узган очракта, аңа түбәндәге документ бирелә: гаиләдә белем алу формасында укыганда – төп гомуми белем турында дәүләт үрнәгендәге документ, мөстәкыйль белем алу формасында укыганда – урта гомуми белем турында дәүләт үрнәгендәге документ.

2.33. Дәүләт йомгаклау аттестациясендә канәгатьләнерлек нәтиҗәләргә ирешкәндә, аттестатка экстерннар тарафыннан белем бирү оешмасындагы уку планының мәҗбүри өлешенә керә торган барлык уку предметлары буенча арадаш аттестациядә алынган билгеләр куела. Белем алу формасы һәм уку формасы аттестатта күрсәтелми.

Документ создан в электронной форме. № 56882-Инф от 25.05.2026. Исполнитель: Переводчики
Страница 15 из 21. Страница создана: 23.05.2026 12:56
ЕМСЭД

2.34. Дәүләт йомгаклау аттестациясен узмаган яки дәүләт йомгаклау аттестациясендә канәгатьләнерлек булмаган нәтиҗәләр алган затларга Оешмада билгеләнгән үрнәк буенча уку турында яисә уку чоры турында белешмә бирелә.

Казан шәһәре Башкарма комитетының
2026 елның 7 маендагы 1580 номерлы
карарына 2 номерлы кушымта
(Форма)

Казан шәһәре Башкарма комитеты
Мәгариф идарәсенең Казан шәһәренең
__________________________ район(-нар)ы буенча
мәгариф бүлегенә
____________________________________________,
[әтисе яки әнисенең (законлы вәкилнең)
фамилиясе, исеме, атасы исеме]
түбәндәге адрес буенча яши:
____________________________________________,
элемтә өчен телефон:_______________________

**БАЛАНЫҢ ГАИЛӘДӘ БЕЛЕМ АЛУ ФОРМАСЫНДА ГОМУМИ БЕЛЕМ АЛУЫ ТУРЫНДА ХӘБӘРНАМӘ**

Әлеге хәбәрнамә белән минем балигъ булмаган балам, __________________________________________________________, туган елы ________,
(балигъ булмаган баланың фамилиясе, исеме, атасының исеме тулысынча)
______ сыйныф укучысы, 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә мәгариф турында»гы федераль законның 63 статьясының 5 өлеше, Россия Федерациясе Гаилә кодексының 63 статьясының 2 пункты нигезендә, гаиләдә белем алу формасында гомуми белем алачагы турында җиткерәм. Белем алу формасын сайлау турында карар баланың фикерен исәпкә алып кабул ителде.

2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә мәгариф турында»гы федераль законның 44, 55 статьялары нигезендә балигъ булмаган укучының әти-әниләренең (законлы вәкилләренең) белем алу өлкәсендәге хокуклары, бурычлары һәм җаваплылыгы белән таныштым.

Арадаш, йомгаклау һәм (яисә) дәүләт йомгаклау аттестациясен экстерн рәвештә узу өчен түбәндәге гомуми белем бирү оешмасы билгеләнде: _____________________________________________________________.
(оешманың тулы исемен күрсәтергә)

Россия Федерациясенең «Шәхси мәгълүматларны саклау турында»гы федераль законы нигезендә баламның, үземнең шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә риза.

Дата ______________________

Имза ________________ (_________________________________)
(имзаның аңлатмасы)

_______________

Документ создан в электронной форме. № 56882-Инф от 25.05.2026. Исполнитель: Переводчики
Страница 17 из 21. Страница создана: 23.05.2026 12:56
ЕМСЭД

Казан шәһәре Башкарма комитетының
2026 елның 7 маендагы 1580 номерлы
карарына 3 номерлы кушымта
(Форма)

Казан шәһәре Башкарма комитеты
Мәгариф идарәсенең Казан шәһәренең
_________________________ район(-нар)ы буенча
мәгариф бүлегенә

___________________________________________,
(экстернның фамилиясе, исеме, атасы исеме)
түбәндәге адрес буенча яши:
___________________________________________,
элемтә өчен телефон:_______________________

**МӨСТӘКЫЙЛЬ БЕЛЕМ АЛУ ФОРМАСЫНДА**
**ГОМУМИ БЕЛЕМ АЛУ ТУРЫНДА**
**ХӘБӘРНАМӘ**

Әлеге хәбәрнамә белән мин, ____________________________________________,
(фамилия, исем, атасы исеме тулысынча)
туган елы ________, ______ сыйныф укучысы, 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә мәгариф турында»гы федераль законның 63 статьясының 5 өлеше, Россия Федерациясе Гаилә кодексының 63 статьясының 2 пункты нигезендә, мөстәкыйль белем алу формасында гомуми белем алачагым турында җиткерәм.

2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә мәгариф турында»гы федераль законның 44, 55 статьялары нигезендә белем алу өлкәсендәге хокуклар, бурычлар һәм җаваплылык белән таныштым.

Арадаш, йомгаклау һәм (яисә) дәүләт йомгаклау аттестациясен экстерн рәвештә узу өчен түбәндәге гомуми белем бирү оешмасы билгеләнде: ______________________________________________________________.
(гомуми белем бирү оешмасының тулы исемен күрсәтергә)

Россия Федерациясенең «Шәхси мәгълүматларны саклау турында»гы федераль законы нигезендә шәхси мәгълүматларымны эшкәртүгә риза.

Дата ______________________

Имза _________________ (_________________________________)
(имзаның аңлатмасы)

________________

Казан шәһәре Башкарма комитетының
2026 елның 7 маендагы
1580 номерлы карарына
4 номерлы кушымта
(Форма)

**Хөрмәтле __________________________!**

Гомуми белем бирү оешмаларында уку процессы 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә мәгариф турында»гы федераль закон (алга таба – 273-ФЗ номерлы Федераль закон) нигезендә оештырылган.

273-ФЗ номерлы федераль законның 63 статьясындагы 4 өлеше нигезендә гомуми белем алу формасы һәм конкрет төп гомуми белем бирү программасы буенча уку формасы балигъ булмаган укучының әти-әнисе (законлы вәкилләре) тарафыннан билгеләнә. Балигъ булмаган укучының әти-әнисе (законлы вәкилләре) гомуми белем алу формасын һәм уку формасын сайлаганда, баланың фикере исәпкә алына.

273-ФЗ номерлы федераль законның 63 статьясындагы 5 өлеше нигезендә муниципаль районнарның, муниципаль округларның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнары һәр дәрәҗәдә гомуми белем алырга хокукы булган һәм тиешле муниципаль берәмлекләр территорияләрендә яшәүче балаларны һәм балаларның әти-әниләре (законлы вәкилләре) билгеләгән белем алу формаларын исәптә тота. Балаларның әти-әниләре (законлы вәкилләре) гаиләдә белем алу формасында гомуми белем алу формасын сайлаган очракта, әти-әниләр (законлы вәкилләр) бу сайлау турында муниципаль районның, муниципаль округның яисә шәһәр округының үзләре яши торган территорияләрдәге җирле үзидарә органына хәбәр итәләр.

Белем бирү программасын гаиләдә белем алу формасында үзләштерүгә күчү турында карар кабул иткәндәге төп таләпләр Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгының 2021 елның 22 мартындагы 115 номерлы әмере белән расланган Төп гомуми белем бирү программалары – башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирүнең мәгариф программалары буенча белем бирү эшчәнлеген оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибе (алга таба – Тәртип) белән җайга салынган.

Тәртипнең 5 пунктында билгеләнә: балигъ булмаган укучының әти-әнисе (законлы вәкилләре) гаиләдә белем алу формасында гомуми белем алу формасын сайлаганда, әти-әниләр (законлы вәкилләр), укучыны гаиләдә белем алуга күчүгә бәйле рәвештә белем бирү оешмасыннан чыгару турында әмер расланган вакыттан алып 15 календарь көн эчендә яисә гаиләдә белем алу планлаштырылган уку елы башланырга кимендә 15 календарь көн кала, территориясендә яши торган муниципаль районның яисә шәһәр округының җирле үзидарә органына мондый сайлау турында хәбәр итәләр.

Югарыда язылганны исәпкә алып, Сез һәм Сезнең балагыз белем бирү оешмасыннан читтә гаиләдә белем алу формасында белем бирү программаларын үзләштерүне сайлаган очракта, кабул ителгән карар турында Сез җирле үзидарә органына – Казан шәһәре муниципаль берлеге Башкарма комитеты Мәгариф

идарәсенең _______________________________________________ район(нар)ы буенча мәгариф бүлегенә (__________________________________________________________)
(адресын, телефон номерын күрсәтергә)

шәхсән килгән вакытта, документларның төп нөсхәләрен (балигъ булмаган укучының әтисе-әнисенең (законлы вәкиленең) паспорты, экстернның туу турында таныклыгы яки паспорты, экстернның яшәү урыны буенча теркәлү турында документы) күрсәтеп, язма рәвештә яисә, Казан шәһәре Башкарма комитеты Мәгариф идарәсенең Интернет аша кабул итү сәхифәсеннән (https://obrazovanie.kzn.ru) файдаланып, Казан шәһәре Башкарма комитеты Мәгариф идарәсе башлыгы адресына, Россия Федерациясенең бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләре порталында идентификация үтеп, документларның (балигъ булмаган укучының әтисе-әнисенең (законлы вәкиленең) паспорты, укучының туу турында таныклыгы яки паспорты, укучының яшәү урыны буенча теркәлү турында документы) күчермәләрен теркәп, электрон рәвештә.

Шуңа игътибар бирәбез: Тәртипнең 27 пункты нигезендә балигъ булмаган укучының әти-әнисе (законлы вәкилләре) арадаш һәм (яисә) дәүләт йомгаклау аттестациясен узу өчен, шул исәптән муниципаль районның яки шәһәр округының үзләре яши торган территория караган җирле үзидарә органы тәкъдимнәренә нигезләнеп, белем бирү оешмасын сайлыйлар.

Балигъ булмаган укучыларның әти-әнисе (законлы вәкилләре) теләге буенча аттестация узу өчен мәгариф оешмасы бер уку елына, гомуми белем алуның бөтен чорына яисә конкрет аттестация узу чорына билгеләнергә мөмкин.

Шулай итеп, Сез балигъ булмаган укучының әти-әнисе (законлы вәкилләре) тарафыннан Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты Мәгариф идарәсенең ___________________________________________ район(нар)ы мәгариф бүлегенә арадаш һәм (яисә) йомгаклау (дәүләт йомгаклау) аттестациясен узу өчен оешма сайлавы турында мәгълүмат тапшырудан баш тарткан очракта, 1999 елның 24 июнендәге 120-ФЗ номерлы «Балигъ булмаганнарның күзәтүчесез калуларын һәм аларның хокук бозуларын профилактикалау системасы нигезләре турында»гы федераль законның 9 статьясы нигезендә күзәтүчесезлекне һәм хокук бозуларны профилактикалау системасы органнары һәм учреждениеләре балигъ булмаганнарның (шул исәптән мәгариф оешмалары һәм муниципаль берәмлекләрнең мәгариф идарәләре) үз вәкаләтләре чикләрендә хокук бозулары турында кичекмәстән түбәндәгеләргә мәгълүмат бирү хокукын үзләрендә калдыралар:

- прокуратура органнарына;
- балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясенә;
- опека һәм попечительлек органнарына;
- эчке эшләр органнарына.

**Бүлек башлыгы**

**Хөрмәтле ________________________!**

Сезнең тарафтан теркәп бирелгән ________________________________________
(мәгариф оешмасының атамасы)

________елның _____ ____________________ _______ номерлы әмере балагызны, ____________________________________________________________________________,
(балигъ булмаган затның фамилиясе, исеме, атасының исеме)

өстәмә гомуми белем бирү программасы – «__________________________________________» өстәмә гомуми үстерү программасы
(атамасын күрсәтергә)

буенча белем алуга кабул итү фактын раслый.

Әлеге программа ______________________________________ белем бирүнең
(программаларны үзләштерү дәрәҗәсен күрсәтергә)

федераль дәүләт мәгариф стандартлары һәм тиешле федераль төп гомуми белем бирү программалары нигезендә эшләнгән төп белем бирү программасы булып тормый.

__________________ булган лицензияләр реестрыннан реестр өземтәсе буенча
(датаны күрсәтергә)

белем бирү оешмасы – _____________________________________________________
(белем бирү оешмасы атамасы)

(төп дәүләт теркәве номеры_______________, салым түләүченең тәңгәлләштерү номеры ___________________________[1]), белем бирүнең ___________________________________________ түгел, бары тик өстәмә
(программаларны үзләштерү дәрәҗәсен күрсәтергә)

программаларны гамәлгә ашыра.

Шулай итеп, Сезнең тарафыннан тапшырылган мәгълүматны исәпкә алып, балагыз хәзерге вакытта белем бирүнең ________________________________________
(программаларны үзләштерү дәрәҗәсен күрсәтергә)

мәгариф программасын үзләштерүгә керешмәгән, шунлыктан Россия Федерациясе Конституциясе белән гарантияләнгән һәркем ала алырлык һәм бушлай гомуми белем алу хокукын бозу билгеләре күренә.

**Бүлек башлыгы**

_______________

[1] Белем бирү эшчәнлеген алып баруга лицензиясе һәм дәүләт аккредитациясе турында таныклыгы булуны Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек федераль хезмәте сайтында салым түләүченең тәңгәлләштерү номеры буенча тикшерергә мөмкин:

- лицензия: https://obrnadzor.gov.ru/gosudarstvennye-uslugi-i-funkczii/gosudarstvennye-uslugi/liczenzirovanie-obrazovatelnoj-deyatelnosti/svodnyj-reestr-liczenzij/;

- дәүләт аккредитациясе турында таныклык: https://islod.obrnadzor.gov.ru/accredreestr/.